СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.09.2024 г.Лениногорск № 60

Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 54 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 54 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4.6.3 пунктта «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

4.7.8 пунктта «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә»сүзләренә алмаштырырга;

4.9.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел»;

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының Экология, табигатьтән файдалану, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск
муниципаль районы
Башлыгы вазифаларын башкаручы С.В.Тимаков